РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОЧЕЧКАБСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЧӘЧКАП
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

18 июль 2022ел　　　　№ 24

ТР Буа муниципаль районы
Яңа Чәчкап авыл җирлегенең салым
чыгымнары исемлеген формалаштыру
һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә
үзгәрешләр кертү турында

РФ Бюджет кодексының 174.3 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2009 еллның 22 июнендәге 796 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә, ТР Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган ТР Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. III бүлек:

11 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

11. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең салым чыгымнарының максатка ярашлылыгы критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

Россия Федерациясе субъектының (муниципаль берәмлекнең) дәүләт (муниципаль) программаларын һәм (яисә) Россия Федерациясе субъектының (муниципаль берәмлекнең) дәүләт программаларына (муниципаль программаларга)карамаган социаль-икътисадый сәясәт максатларына һәм (яисә) Россия Федерациясе субъектының (муниципаль берәмлекнең) социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламаларны куллану өчен потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны 5 еллык чорда күрсәтелгән ташламаларга ихтыяҗ булу.

Салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсе генә булса да туры килмәсә дә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге башкарма комитетына түләүчеләргә ташламаларны саклау (аныклау, юкка чыгару) турында тәкъдимнәр тапшырырга кирәк.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Яңа Чәчкап авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе Н.Х. Хисамов